ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.09.2019 Алексеевск ш.т.б. № 386

**2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерлары тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товар, эш, хезмәт күрсәтүләргә субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга, норматив хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм**

1. 2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен расларга (Кушымта №1).

2. 2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең юл картасын расларга (Кушымта №2).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында, Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендәге http:/alekseevskiy.tatarstan.ru адресы буенча районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.09.2019 № 386 карарына
1 нче кушымта

**2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе**

1. Субсидияләр бирү турында Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча эшмәкәрлек белән шөгыльләнмәгән эшчәнлек рәвеше.

Шәхси ярдәмче хуҗалык граждан яисә граждан һәм аның белән бергә яшәүче һәм (яисә) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыручы гаилә әгъзалары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яисә) сатып алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында алып барыла.

Субсидияләр - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, алынмаган керемнәрне һәм (яисә) финанс белән тәэмин итүне (реализацияләүне) төзүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә торган Алексеевск муниципаль районы бюджеты түләүләре.

Субсидия алучы - шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яки) сатып алынган җир кишәрлегендәге шәхси ихтыяҗны канәгатьләндерүче гражданин яисә гражданин һәм аның белән бергә яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы аның гаилә әгъзалары.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртиптә күрсәтелгән актларда билгеләнгән акчалар чикләрендә һәм срокларда субсидияләр түләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты.

1.2. Субсидияләр бирүнең максаты - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә сөт сыерларының баш санын саклап калуны һәм терлекчелек продукциясе җитештерүне тәэмин итү, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт сыерларының баш санын арттыруны стимуллаштыру тора һәм бирелгән суюсидияләр бары тик күрсәтелгән максат нигезендә генә тотылырга тиеш.

1.3. Бюджет акчалары, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, тиешле финанс елына (тиешле финанс елы һәм план чоры) субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары рәвешендә билгеләнгән тәртиптә Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – район Башкарма комитеты) алучыга җиткерелгән.

1.4. Сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр (алга таба-субсидияләр) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы составына керүче торак пунктларда теркәлгән һәм Татарстан Республикасы

Алексеевск муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелә, алар терлекләрнең баш санын 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр арттыралар.

Субсидия гариза нигезендә бер тапкыр бирелә.

1.5. Финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидияләр калдыклары булмаган һәм мондый нигезләмәләрне Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килешенеп, район Башкарма комитеты тарафыннан бюджет акчаларын алучы буларак, әлеге акчаларга ихтыяҗ булу турында килешүгә керткәндә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

1.6. Субсидияләр Казан шәһәренең «АкБарс» банкында (Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә казна ярдәме буларак тиешле субсидияләрдән тыш) субсидия алучыларга ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерелә.

## 2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе.

2.1. Субсидияләр алу өчен гражданнар Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге тәртипкә 1 кушымта нигезендә кабул ителгән формада гариза;

гариза бирүченең паспорт күчермәсе;

халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларын исәпкә алу буенча электрон хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

әлеге тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә кабул ителгән формада субсидия бирү өчен исәп-хисап;

әлеге тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә кабул ителгән формада шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, бер һәм аннан күбрәк сөт сыеры булган гражданга 2019 елда терлек тотуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияне максатчан файдалану турында йөкләмә;

банк реквизитлары;

2019 елда планлы ветеринария чараларын уздыру буенча ветеринария хезмәте (оешма) белешмәсе;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

әлеге тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә кабул ителгән формада Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан 2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында килешү.

2.2. Районның башкарма комитеты:

гаризаларны бирелгән көнне үк субсидияләр бирү турында журналга теркәп куя, әлеге журнал мөһер сугылган һәм ябыштырылган булырга тиеш. Әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә бирелгән документларны керү датасы, журналда теркәлү тәртибе буенча карыйлар. Документлар гаризаны теркәгән көннән соң 10 көн эчендә карала;

әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерә;

Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә субсидияләр бирүгә җыелма исәп-хисап белешмәләре төзи.

2.3. Субсидия алучыга субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

күчермәләрдә субсидияләр алуга дәгъва кылучылар тарафыннан бирелә торган документлар нотариаль яктан таныкланмаган яки документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәгән;

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.4. Субсидияләр һәр арттырылган баш терлеккә 5000 сум исәбеннән электрон хуҗалык кенәгәсе мәгълүматлары нигезендә бирелә. Түләү квартал йомгаклары буенча Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан бирелә.

Агымдагы финанс елында, бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйлерәвештә, әлеге тәртиптә күрсәтелгән сайлап алу критерийларына һәм (яисә) критерийларына турыкилгән субсидия алучыга субсидия бирү мөмкин булмаган очракта, чираттагы финанс елында субсидияләр әлеге категорияләргә һәм (яисә) сайлап алу критерийларына кабат тикшерүдән башка бирелә.

2.5. Әлеге тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә Район Башкарма комитеты һәм тиешле авыл җирлеге башкарма комитеты арасында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының тиешле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан субсидия алучының шәхси ярдәмче хуҗалыгында терлекләрнең баш саны буенча кварталлык хисап бирү турында килешүләр төзелә.

2.6. Субсидия алучылар килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына туры килергә тиешле таләпләр:

субсидия алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булырга тиеш;

субсидия алучыларның әлеге Тәртип нигезендә, субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурыч нигезендә, аның бюджетына субсидияләр бирү планлаштырылган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмаска тиеш;

субсидияләр алучылар әлеге тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан акчалар алырга тиеш түгел.

2.7. Субсидия бирүнең мәҗбүри шарты - агымдагы елның кварталы йомгаклары буенча сөтчелек сыерларының баш санын арттыру.

2.8. Районның башкарма комитеты бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм субсидияләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счетларыннан (счет № 40204810900000025 Татарстан Республикасының НБ - бүлеге, БИК 049205001, ЛБ 055040001-Башкарма комитет) җиде көн эчендә гражданнарның банк счетларына әлеге тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә күчерә.

## 3. Хисап бирүгә таләпләр.

3.1. Бирелгән субсидияләр, субсидияләрне максатчан кулланмау фактларын ачыклау һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр һәм субсидияләр алу өчен документлар тапшыру буенча район Башкарма комитетының тиешле таләбен алу датасыннан алып, алтмыш көн эчендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемөнә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

3.2. Районның башкарма комитеты квартал саен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советына 2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән бюджет акчаларыннан файдалану турында хисап тапшыра.

3.3. Гражданнар тарафыннан бирелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык әлеге Тәртип нигезендә субсидия алу өчен гариза бирүче гражданнарга йөкләнә. Коррупциягә каршы законнарны үтәү район Башкарма комитетының вазифаи затларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

3.4. Бюджет акчаларының максатчан кулланылышын Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары контрольдә тота.

3.5. Субсидияләр финанс тәэминаты чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелә.

## 4. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру турындагы таләпләр.

4.1. Район башкарма комитеты, акчаларны баш бүлүче буларак, шулай ук Алексеевск муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары әлеге Тәртип нигезендә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тота.

4.2. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләрен алучы агымдагы финанс елында субсидияләр бирү, субсидияләр бирү турындагы килешүләрдә каралган очракларда кире кайтару, шулай ук аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияләрне тиешле бюджетка кире кайтару тәртибе.

Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, агымдагы финанс елында субсидия алучы хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия акчаларын кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

Башкарма комитет, финанс хисап елында субсидия алучы тарафыннан файдаланылмаган субсидия калдыгы ачыклангannan соң, 7 эш көне эчендә субсидия алучыга акчаны ирекле рәвештә кире кайтару турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать җибәрә.

Субсидия калдыгы түләү йөкләмәләрен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты счетына күчерү юлы белән кире кайтарылырга тиеш.

4.3.Башкарма комитет субсидия бирү шартларын бозган өчен субсидия алучыга мөрәҗәгать җибәрә, акчаны ирекле рәвештә кире кайтару турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта кире кайтару срогы субсидия алучы тарафыннан әлеге хат алынган көннән бер ай тәшкил итә.

4.4.Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 4.2., 4.3 пунктларында күрсәтелгән срокка акчаларны кире кайтармаган очракта, башкарма комитет субсидия суммасын суд тәртибендә түләтү чараларын күрә.

4.5.Субсидияләр кире кайтарылырга тиеш:

- субсидия алучының бюджет акчаларын алучы һәм дәүләт муниципаль финанс тикшерүе органы тарафыннан үткәрелгән тикшерү фактлары буенча ачыкланган аларны биргәндә билгеләнгән шартларын бозган очракта;

- әлеге Тәртипнең 1.4, 2.4 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешмәгән очракта.

2019 елда баш санын арттыру
максатларында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларга сөт сыерларын
тотуга киткән чыгымнарның бер
өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибенә 1нче кушымта

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

______________________________

______________________________дан

______________________________

______________________________

(Ф.И.Аи.,яшәү урыны)

**2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган шәхси ярдәмче хуҗалыкка сөт сыерларын тотуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында гариза**

**Заявление**

Мин, ______________________________________________________________,
(Ф.И.Аи.)

паспорт сериясе ____________ № ____________ ___________________________
_____________________________________________________________________
______________________________бирелгән,______________________________
_________________________________________ адресы буенча яшәүче телефон: ________________________________________, ИНН___________________,
2019 елда бер һәм аннан күбрәк сөт сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкта сөт сыерларын тотуга чыгымнар өлешен каплауга тиешле субсидияне (алга таба - субсидия) бирүегезне сорыйм. Шуны хәбәр итәм: шәхси хуҗалыкта савым сыерларының саны түбәндәге адрес буенча урнашкан: _____________________________________________________________________
1.01.2019 ел торышына (______________________________) баш тәшкил итә.

1. Субсидия бирү тәртибендә катнашу шартлары белән таныштым һәм килешәм.

2. Субсидия алган очракта, һичшиксез түбәндәгеләрне эшләячәкмен:

субсидия алганнан соң ике ел дәвамында сөт сыерларының баш санын киметмәячәкмен;

соралган срокларда хисап тапшырачакмын;

субсидияне максатчан файдаланачакмын - минем шәхси ярдәмче хуҗалыгымдагы сөт сыерларын тотуга счетыма акча кергән көннән алып 3 ай эчендә файдаланырга.

Тәкъдим ителгән документларда яки аларның күчермәләрендә тупланган барлык мәгълүмат чын мәгълүмат булып тора. Мин субсидия бирү документларын карауда катнашучы затлар булуга каршы түгел.

____________ /______________ / "____" __________2019 ел.

(Имза) (Ф.И.Аи.)

2019 елда баш санын арттыру
максатларында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларга сөт сыерларын
тотуга киткән чыгымнарның бер
өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибенә 2нче кушымта

**Шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы һәм 2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган гражданнарга 2019 елда тотуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү турында исәп-хисап белешмәсе**
**2019 елның "___" __________ булган мәгълүматлар буенча.**

| | | |
|---|---|---|
| "Раслыйм"<br>Татарстан Республикасы<br>Алексеевск муниципаль<br>районы Башкарма<br>комитеты җитәкчесе<br>_______________________<br>_______________________<br>(имза) Ф.И.Аи)<br>"_____" _________2019 ел | "Килешенгән"<br>Татарстан Республикасы<br>Алексеевск муниципаль<br>районы ____________<br>авыл җирлеге башлыгы<br>_______________________<br>_______________________<br>(имза) Ф.И.Аи)<br>"_____" _________2019 ел | |

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының ________________ авыл җирлеге буенча
ОКАТО ___________________

| № | ШЯХ хуҗвсы | Яшәү урыны | ИНН | Паспорт мәгълүматлары | Сөт сыерларның саны, баш исәбе | Сөт сыерларның саны, баш исәбе | Бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка субсидия ставкасы, сум | Субсидияләр барлыгы, сум | Баш санының үсеше, |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | квартал башына | квартал ахырына | 5000 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ____________________
авыл җирлеге башлыгы

________________________ /____________________________________
(Ф.И.Аи.) (имза)

2019 елда баш санын арттыру
максатларында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларга сөт сыерларын
тотуга киткән чыгымнарның бер
өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибенә 3 нче кушымта

**Шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы һәм 2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган гражданга 2019 елда карап тотуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияне максатчан файдалану турында йөкләмә**

Мин, ________________________________________________________________,
(Ф.И.Аи.)

паспорт сериясе ____________ № ____________ ____________________________

____________________________________________________________________________

________________________________бирелгән,____________________________________

___________________________________________ адресы буенча яшәүче телефон:

_______________________________________, ИНН______________________________,

түбәндәгеләрне эшләячәкмен:

1. "2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" Башкарма комитет җитәкчесенең __________________________ номерлы карары нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, бер һәм аннан күбрәк сөт сыеры булган гражданнарга бирелгән субсидияне түбәндәге адрес буенча урнашкан шәхси ярдәмче хуҗалыгымда сөт сыерларын асрауга максатчан билгеләү буенча катгый рәвештә кулланачакмын:

__________________________________________________________________________

2. Район комиссиясе әгъзаларына, район башкарма комитеты вәкилләренә алынган субсидияләрнең максатчан кулланылышын тикшерү өчен шәхси ярдәмче хуҗалыкка тоткарлыксыз кертәчәкмен, субсидиядән файдалану турында кирәкле мәгълүмат бирәчәкмен;

3. Сөт сыерларын карау буенча хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырачакмын, сөт сыерларының булган санын, субсидия алган вакыттан алып кимендә 2 календарь ел дәвамында киметмәячәкмен;

4. 1-3 пунктлар үтәлмәгән очракта, алынган субсидияләрне максатчан файдаланмау актын төзегән һәм имзаланган йөкләмәләр шартларын үтәмәгән көннән алып 60 (алтмыш) көн дәвамында Алексеевск муниципаль районы бюджетына субсидияләр суммасын кире кайтарачакмын;

5. Әлеге йөкләмәләргә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр бары тик алар язма рәвештә башкарылган һәм Яклар тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлгә ашырыла. Әлеге йөкләмәдә җайга салынмаган барлык башка мәсьәләләрдә РФ һәм ТР гамәлдәге законнары нормалары кулланылачак. Әлеге йөкләмәләрне имзалаганда яклар андагы төшенчәләрнең һәм билгеләмәләрнең аңлаешсыз булмавы турында белдерә.

Мин. ______________________________________, "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әлеге йөкләмәне төзегәндә һәм үтәгәндә бирелгән шәхси мәгълүматларга караган мәгълүматны эшкәртүгә ризалыгымны белдерәм. Әлеге ризалык төзелгән йөкләмәнең гамәлдә булу срогына тулысынча бирелә (имза салынган вакыттан алып 2 ел).

| |
|---|
| ____________________________________ (Ф.И.Аи.) |
| Паспорт: серия________, № ____________ |
| ____________________________________________________________ ____________________________________________ тарафыннан бирелгән |
| Яшәү урыны : ____________________________________________________________ ____________________________________________________________ |

_________________________/__________________/

2019 елда баш санын арттыру
максатларында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларга сөт сыерларын
тотуга киткән чыгымнарның бер
өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибенә 4 нче кушымта

**___________ авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында бер һәм аннан да күбрәк сөт сыеры булган хуҗалыкларга 2019 елдагы чыгымнарының бер өлешен каплау өчен ярдәм һәм терлекләрнең баш саны турында отчеты 2019 елның "___" __________ булган мәгълүматлар буенча.**

| | | |
|---|---|---|
| "Раслыйм"<br>Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе<br>____________________<br>____________________<br>(имза) Ф.И.Аи)<br>"_____" _________2019 ел | "Килешенгән"<br>Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ____________<br>авыл җирлеге башлыгы<br>____________________<br>____________________<br>(имза) Ф.И.Аи)<br>"_____" _________2019 ел | |

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының ________________
авыл җирлеге буенча
ОКАТО ____________________

| № | ШЯХ хуҗвсы | Яшәү урыны | Сыерларның саны алынган көнгә, баш | Хисап датасына сыерлар саны, баш | Артым саны, баш |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | __ __ 2019ел | __ ___2019 ел | __ ___2019 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Мәгълүматларның дөреслеген раслыйбыз:
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ____________________
авыл җирлеге башлыгы

________________________ / ____________________________________
(Ф.И.Аи.) (имза)

2019 елда баш санын арттыру
максатларында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларга сөт сыерларын
тотуга киткән чыгымнарның бер
өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибенә 5 нче кушымта

**2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга чыгымнар өлешен каплауга Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында ___номерлы КИЛЕШҮ**

Алексеевск ш.т.б "___" _________20___ ел

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба “Башкарма комитет” дип аталачак (Татарстан Республикасы бюджеты акаларын бүлүче), әлеге нигезләмә нигезендә эш итүче БК җитәкчесе Кадыров Н.К. йөзендә һәм алга таба "Субсидия алучы" дип аталучы _________________________ ышанычнамә нигезендә эш итүче ___________________ йөзендә, алга таба Яклар дип аталучылар, әлеге килешүне төзелделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Килешү предметы булып, 2019 елда сөт сыерларының баш санын арттырган шәхси ярдәмче хуҗалыкка сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга __________________________ ( ____________________________ ) сум күләмендә субсидияләр бирү тора.

2. Якларның бурычлары

2.1. Башкарма комитет:

әлеге килешүгә кул куйганнан соң 7 (җиде) эш көне эчендә, 1.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләрне бер тапкыр күчерүне гамәлгә ашыра;

субсидия алучыдан килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар соратып ала.

2.2. Субсидия алучы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

субсидияләрне нәтиҗәле файдалану;

субсидия бирү тәртибен саклау һәм гамәлдәге законнарны үтәү.

2.3. Башкарма комитет таләбе буенча субсидия куллануны раслаучы мәгълүмат һәм документлар, шулай ук финанс тәэминаты чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында оператив мәгълүмат бирә.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Яклар әлеге килешү буенча йөкләмәләрне гамәлдәге законнар нигезендә үтәмәгән өчен җаваплы.

3.2. Яклар форс-мажор хәлләр килеп чыккан очракта, әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

Форс-маж шартлары дигәндә, акыллы караш белән сак эш итүче Яклар, бәйсез сәбәпләр аркасында йөкләмәләрне тиешенчә үти алмый торган шартларның килеп чыгуы аңлашыла, аерым алганда, килешү буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәргә мөмкинлек бирми торган хәлләргә хәрби гамәлләр, табигый бәла-казалар керә.

Форс-мажор шартлары килеп туган очракта, Яклар әлеге хәлләр турында бер-берсенә өч көн эчендә хәбәр итәргә тиеш.

3.3. Үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык тота.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге килешү аңа кул куйган мизгелдән үз көченә керә һәм 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## 5. Башка шартлар

5.1. Яклар арасындагы бәхәсләр сөйләшүләр юлы белән хәл ителә, ә ризалыкка ирешмәгәндә, кызыксынган як тарафыннан Татарстан Республикасы Алексеевск район судына тапшырыла.

5.2. Әлеге килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр ике якның да ризалыгы белән кертелә һәм әлеге килешүгә өстәмә итеп рәсмиләштерелә.

5.3. Әлеге килешү бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

## 6. Якларның реквизитлары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | Субсидия алучы: |
| _______________ /Н.К.Кадыров/ | _____________________/_____________/ |
| М.У. | |
| "___" _________ 20__ ел. | "___" _________ 20__ел. |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
05.09.2019 № 386 карарына
2 нче кушымта

**2019 елда баш санын арттыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга сөт сыерларын тотуга киткән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең**
**ЮЛ КАРТАСЫ**

| № | Чараның эчтәлеге | Үтәү срогы | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларның баш саны турында хисап бирү. | хисап кварталыннан соң килүче айның 1 числосы торышы буенча | Авыл җирлекләре башлыклары,Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2 | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының ОМС бүлегенә субсидия бүлеп бирүгә туры килә торган гражданнардан, 1,2,3,5 номерлы кушымталар нигезендә, документлар пакетын җыю, комплектацияләү һәм бирү. | хисап кварталыннан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча | Авыл җирлекләре башлыклары,Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3 | Субсидия бирү турында гаризаны теркәү | гариза килгән көнне | Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4 | Кергән документларның дөреслеген карау һәм тикшерү. | гаризаны теркәү көненнән соң 10 көн эчендә | Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5 | Субсидия түләү өчен кирәкле акчаларны исәпләү, җыелма исәп-хисап белешмәләре ясау | | Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6 | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына субсидия бүлеп бирү турында карар проектын әзерләү. | | Алексеевск муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 7 | Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү | Алексеевск муниципаль | Алексеевск муниципаль районы Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турындагы килешү (әлеге Тәртипкә 5 кушымта) һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының субсидия бирү турындагы карары нигезендә субсидия түләү. | районы Башкарма комитетының субсидия бүлеп бирү турында килешүенә (әлеге Тәртипкә 5 кушымта) һәм карарына кул куелганнан соң җиде көн эчендә | комитетының исәп-хисап бүлеге |
| 8 | Максатчан файдалану турындагы йөкләмәнең үтәлешен контрольдә тоту. | даими | Алексеевск муниципаль районының контроль - хисап Палатасы, авыл җирлекләре башлыклары |